ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2019 елның 3 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасары Р.Г. Сәхиева, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 1.1 пунктының дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел

хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъва белдерелә торган норма буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме шул исәптән тормыш хәле авыр булган (каты авыру, шул исәптән якын туганы (хатыны (ире), атасы яки анасы, баласы) дәвалануга, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына керми торган кыйммәтле дарулар яки медицина әйберләре сатып алуга китергән; янгын чыгу, су басу яки гражданга шактый зур зыян салган табигый бәла-каза; гражданның тереклек эшчәнлеген ул мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмаслык итеп объектив боза торган башка хәлләр) гражданнарга күрсәтелә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.Н. Юсипова — ялгыз яшәүче пенсионер һәм ул Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артып китә торган пенсия (8823 сум күләмендә) ала һәм аның башка өстәмә керемнәре юк. Ул күрсәткәнчә, торак-коммуналь хезмәтләргә түләүдә бурычлары булганлыктан, суд карары нигезендә ай саен аның пенсиясеннән билгеле бер сумма тотып калына, шуның нәтиҗәсендә аның яшәргә аена 2912 сум акчасы кала. Аның фикеренчә, әлеге бурыч аның фатирына җылылык энергиясен тулысынча биреп җиткермәгән идарәче компания гаебе белән барлыкка килгән. Төрле дәүләт органнарына һәм муниципаль органнарга мөрәҗәгать итүенә карамастан, хәл үзгәрмәгән, шуның нәтиҗәсендә ул күрсәтелмәгән хезмәтләр өчен түләүне туктатырга мәҗбүр булган. Аның раславынча, 2014 елда җылылык системасын төзекләндергәннән соң, идарәче компания түләмәгән еллары өчен аннан түләтү турында карар кабул иткән.

Мөрәҗәгать итүче үзенең шикаятендә хәзерге вакытта авыр тормыш хәлендә калуы, әмма, шуңа карамастан, аның җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында урнаштырылган яшәү минимумы күләменнән артып киткәнлектән, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән

тәэмин итү һәм социаль ярдәм министрлыгы аңа дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүдән баш тартуы турында белдерә.

Моннан тыш, гражданка Г.Н. Юсипова дәгъва белдерелә торган норманың «гражданның тереклек эшчәнлеген ул мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмаслык итеп объектив боза торган башка хәлләр» турында сүз барган өлешендә билгесезлек булу турында белдерә. Ул, әлеге хәл аның тормыш эшчәнлеген объектив рәвештә боза, чөнки «башка хәлләр» билгеләмәсе, аның асылыннан чыгып караганда, дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турындагы карар кабул итүче вазыйфаи заттан гына тора, чөнки тикшерелә торган Нигезләмәдә бу уңайдан башка аңлатмалар юк дип саный. Шуның нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүче хокукый күрсәтмәләрне гамәлгә ашыручыга аны кулланганда үзлегеннән киң сайлау иреге бирелү дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән күпсанлы нигезсез баш тартуга китерергә мөмкин дип саный.

Югарыда әйтелгәннәр нигезендә, гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүнең хокукый һәм оештыру нигезләре «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба шулай ук — Федераль закон) билгеләнгән.

Югарыда күрсәтелгән Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары аз керемле гаиләләргә, аз керемле ялгыз яшәүче гражданнарга, реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга һәм гражданнарның әлеге Федераль законда каралган

башка категорияләренә дәүләт социаль ярдәменең, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күләмнәрен, билгеләү һәм түләү шартларын һәм тәртибен ачыклый торган законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итә.

Федераль закон нигезендә, шулай ук авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль ярдәм күрсәтүнең адреслы рәвешләре нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән тикшерелә торган Нигезләмә расланган, анда гражданнарның аерым категорияләренә, дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтүнең механизмы һәм шартлары билгеләнә. Шул ук вакытта мондый ярдәм үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләргә һәм аз керемле ялгыз яшәүче гражданнарга күрсәтелә (1.1 пункт). Шуңа тиңдәш хокукый җайга салу Федераль законның 7 статьясындагы беренче өлешендә дә бар. Димәк, федераль законнарда һәм республика законнарында каралу нигезендә, әлеге ярдәмне алу өчен төп шартларның берсе булып гражданнарның җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булуы тора.

Моннан тыш, «гражданның тереклек эшчәнлеген ул мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмаслык итеп объектив боза торган башка хәлләр» билгеләмәсе «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законның «авыр тормыш хәле» дигән төп төшенчә кертелгән һәм ул гражданның тереклек эшчәнлеге шартларын авырайта һәм ул аның яисә аларның нәтиҗәләрен мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмый торган шарт яисә шартлар буларак билгеләнгән 1 статьясы нигезләмәләренә туры килә. Шул ук вакытта әлеге Федераль закон авыр тормыш хәлен билгеләүнең нинди дә булса критерийларын кертми, шулай ук Россия Федерациясе субъектларына авыр тормыш хәлләре исемлеген һәм критерийларын билгеләү хокукын бирми. Үзенең эчтәлеге һәм

мәгънәсе ягыннан тиңдәш «авыр тормыш хәле» төшенчәсе Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2005 елның 30 декабрендәге 532-ст номерлы боерыгы белән расланган «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Терминнар һәм билгеләмәләр» ГОСТ Р 52495-2005 Россия Федерациясе милли стандартының 2.1.5 пунктында да беркетелгән һәм «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442 номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешендә дә гражданнарны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗларга кертүнең төгәл критерийлары беркетелгән.

Шулай итеп гражданка Г.Н. Юсипова дәгъва белдергән Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Россия Федерациясе субъектларына федераль законнарда бирелгән вәкаләтләр кысаларында, аны гражданнарның аерым категорияләренә карата, шул исәптән социаль контракт нигезендә, куллану мөмкинлеген исәпкә алып кабул ителгән, һәм әлеге норматив хокукый акт Федераль законда билгеләнгәннән аерылып тора торган тәртиптә кулланыла алмый һәм, шул рәвешчә, үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән шикаятьтә күрсәтелгән яктан мөрәҗәгать итүченең дә, конституциячел хокукларын бозучы буларак санала алмый, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Шикаять эчтәлегеннән аңлашылганча, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турында нигезләмәнең 1.1 пунктының тикшерелә торган дүртенче абзацының конституциячеллегенә формаль төстә дәгъва белдереп, асылда, аның конкрет

эшенә кагылышлы чынлыктагы хәлләрне исәпкә алып, кулланылырга тиешле хокукый нормаларның сайлануы һәм казуаль аңлатылуы дөреслеген тикшерүне таләп итә, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул билгеләнгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Әлеге шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 40-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**